# КАРАР

**2019 елның 29 ноябре** **№ 1**

**Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең Аман-Ошторма авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәсе турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 29 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), ялгыз аналар, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең Аман-Ошторма авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2020 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

Аман-Ошторма авылында балалар мәйданчыгы төзелеше, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Аман-Ошторма авылында юлларны кардан чистарту.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 67 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 41.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 41 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге Аман-Ошторма авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәләне: «I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), ялгыз аналар, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең Аман-Ошторма авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2020 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны

түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы

Аман-Ошторма авылында балалар мәйданчыгы төзелеше, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Аман-Ошторма авылында юлларны кардан чистарту.

«РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Березняк авыл җирлеге башлыгы: Р.Ф. Шәрипов